РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 18 ноябре № 60

Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы:

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турындагы кушымта итеп бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 18 ноябрендәге
60 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәре территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турындагы
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – муниципаль контроль).

1.2. Муниципаль контроль предметы булып, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның һәм гражданнарның (алга таба – контрольдә торучы затларның) торак законнары, энергияне сак тоту турында һәм муниципаль торак фондына карата энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәве, ә атап әйткәндә:

1) торак фондыннан файдалану һәм сакланышы, шул исәптән торак урыннардан файдалану, аларны куллану һәм карап тоту, күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренең гомуми милкен куллану һәм карап тоту, күпфатирлы йорттагы торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү тәртибенә, күпфатирлы йортта урыннарны яңадан планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр;

2) капиталь ремонт фондларын формалаштыруга карата таләпләр;

3) күпфатирлы йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яки) эш башкаручы, күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны оештыру һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләр;

4) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә карата таләпләр;

5) күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле булмаган сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән озынлыктан артып киткән тәнәфесләр белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

6) күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләре һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

7) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре;

8) күпфатирлы йортлар урыннарының һәм торак йортларның файдалана торган энергия ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше һәм энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре;

9) ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр;

10) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен урыннар алу мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр;

11) социаль файдаланудагы наемга алынган йортларда торак урыннары бирүгә карата таләпләр.

Шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше муниципаль контроль предметы булып тора.

1.3. Муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объекты) булып тора:

- алар кысаларында мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиеш булган контрольдә торучы затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы), шул исәптән эшчәнлекне, гамәлләрне (гамәл кылмау) гамәлгә ашыручы контрольдә торучы затларга карата куелган таләпләр;

- контрольдә торучы затларның эшчәнлеге, шул исәптән мәҗбүри таләпләр куела торган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләренең нәтиҗәләре.

1.4. Контроль объектларын исәпкә алу түбәндәгеләрне булдыру юлы белән башкарыла:

- контроль чараларның бердәм реестры;

- ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән башка дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системалары.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 16 статьясындагы 2 өлеше һәм 17 статьясындагы 5 өлеше нигезендә контроль орган тарафыннан мәгълүмат системасын кулланып контроль объектларын исәпкә алу алып барыла.

1.5. Муниципаль контроль Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты (алга таба – Контроль орган) тарафыннан башкарыла.

1.6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру эшчәнлеге белән идарә итүне Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе гамәлгә ашыра.

1.7. Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Контроль органның (алга таба – инспекторлар) боеру акты белән билгеләнә.

1.8. Инспекторның хокуклары һәм бурычлары:

1.8.1. Инспектор бурычлы:

1) Россия Федерациясе законнарын, контрольдә торучы затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә гамәлгә ашырырга, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итү турында тәкъдимнәр әзерләгәнчегә кадәр, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, Контроль орган карарларын үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

3) контроль чаралар үткәрергә һәм закон нигезендә һәм аларның билгеләнеше нигезендә бары тик хезмәт вазыйфаларын башкарганда һәм контроль чараларның бердәм реестрында тиешле мәгълүмат булган очракта гына, контроль чаралар башкарырга, ә контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлек иткән очракта, хезмәт таныклыгын, федераль законнарда каралган башка документларны күрсәткәндә генә, мондый чараларны үткәрергә һәм мондый гамәлләрне кылырга;

4) контроль чаралар үткәргәндә, гыйбадәт кылуга, башка дини йолаларга һәм тантаналарга карата ихтирамсызлык күрсәтмәскә, аларны уздыруга комачауламаска, шулай ук дини оешмаларның эчке билгеләнешләрен бозмаска;

5) контрольдә торучы затларның, аларның вәкилләренең катнашуына комачауламаска, ә контрольдә торучы затларның, аларның вәкилләренең ризалыгы белән Эшкуарларның хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилнең яисә аның иҗтимагый вәкилләренең, Волгоград өлкәсендә эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең контроль чаралар үткәргәндә (контроль органнарның контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлеге таләп ителми торган контроль чаралардан тыш) һәм федераль законда һәм әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында каралган очракларда, консультация бирергә;

6) контрольдә торучы затларга, аларның контроль чаралар уздырганда катнашучы вәкилләренә, муниципаль контроль предметына караган мәгълүмат һәм документлар, шул

исәптән федераль законда мондый килештерү каралган очракта, контроль чараны үткәрүне прокуратура органнары белән килештерү турында белешмәләр бирергә;

7) контрольдә торучы затларны, аларның вәкилләрен тикшерү чаралары һәм контроль чаралар предметына караган контроль гамәлләр нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) контрольдә торучы затларны, аларның вәкилләрен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган һәм контроль чара предметына караган мәгълүмат һәм (яки) документлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның  ачыкланган бозулар авырлыгына, аларның закон белән саклана торган кыйммәтләр өчен потенциаль куркынычларга туры килүен исәпкә алырга, шулай ук контрольдә торучы затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүне, аларның мөлкәтенә хокуксыз зыян (зарар) салуны булдырмаска;

10) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдергәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

11) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән контроль чаралар үткәрү һәм контроль гамәлләр кылу срокларын үтәргә;

12) контрольдә торучы затлардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган яисә дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында булган документлар һәм башка белешмәләр таләп итмәскә.

1.8.2. Тикшерү чарасын үткәргән вакытта инспектор үз вәкаләтләре чикләрендә һәм үткәрелә торган контроль гамәлләр күләмендә хокуклы:

1) хезмәт таныклыгын күрсәткәндә һәм контроль чара үткәрү турында контроль органы карары белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә, федераль законнарда башкача каралмаган булса, җитештерү объектларында тоткарлыксыз булырга (карарга);

2) мәҗбүри таләпләрне үтәүгә кагылышлы барлык документлар, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция яки закон тарафыннан саклана торган башка серләрне үз эченә алган документлар белән танышырга;

3) контрольдә торучы затлардан, шул исәптән контрольдә тотыла торган оешмаларның җитәкчеләреннән һәм башка хезмәткәрләреннән контроль чаралар үткәргәндә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары буенча язмача аңлатмалар бирүне, шулай ук документларны күчерүне, фото - һәм видеога төшерүне таләп итәргә;

4) тикшерү чарасы предметына һәм күләменә караган өлешендә техник документлар, электрон мәгълүматлар базалары, контрольдә торучы затларның мәгълүмат системалары белән танышырга;

5) контрольдә торучы зат тарафыннан контроль чаралар үткәргәндә соралган документларны һәм материалларны тапшырмау яки вакытында тапшырмау, вазыйфаи затларны һәм (яки) контрольдә торучы зат хезмәткәрләрен сораштыру үткәрү мөмкинлеге булмау, бинага керү мөмкинлеген чикләү, контроль чараны гамәлгә ашыру буенча башка чараларга комачаулау фактлары буенча актлар төзергә;

6) контрольдә торучы затларга мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча күрсәтмәләр бирергә, контрольдә торучы затлар тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында һәм бозылган нигезләмәне торгызу турында карарлар кабул итәргә;

7) Инспекторга каршы тору яисә куркыныч янаган очракларда, «Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, полиция органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә.

1.9. Контроль органы судка гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы яисә торак милекчеләре ширкәте, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен бозып кабул ителгән карарны гамәлдә түгел дип тану турында;

2) мондый ширкәт яки мондый кооператив уставының, мондый ширкәт яки мондый кооператив уставына кертелгән үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләренә туры килмәвен бетерү турында кисәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта яисә мондый ширкәт яки мондый кооператив төзү тәртибен бозу ачыкланган очракта, әгәр бу хокук бозулар котылгысыз характерда булса, торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын гамәлдән чыгару турында;

3) күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсен яисә күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләрне башкару буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәсен, идарәче оешманы сайлап алу турында Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен бозуларны бетерү турында, күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен раслау турында һәм аны төзү турында, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсен яисә күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яки) үтәү буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәсен төзү турында, әлеге шартнамәләрнең шартларын раслау турында кисәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, гамәлдә түгел дип тану турында;

4) аларның мөрәҗәгатьләре буенча күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең, торак урыннарны наемга алучыларның һәм башка файдаланучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау яки, мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, билгесез затлар даирәсенең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга;

5) Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килмәвен бетерү турында кисәтмәне билгеләнгән вакытта үтәмәгән очракта, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыны наем шартнамәсен гамәлдә түгел дип тану турында;

6) кисәтмәне үтәргә мәҗбүр итү турында.

1.10. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.11. Контрольдә торучы затларга контроль органның вазыйфаи затлары һәм башка вәкаләтле затлар башкарган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында хәбәр итү күрсәтелгән гамәлләр һәм карарлар турында белешмәләрне контрольлек (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында мәгълүматларны урнаштыру, шулай ук аларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм электрон формада дәүләт һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура аша контрольдә торучы затларга җиткерү юлы белән хәл ителә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләр)» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (алга таба – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы) һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы аша.

## 2. Зыян (зарар) китерүнең риск категориясе

2.1. Муниципаль торак контроле профилактик чараларны һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларның эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган мәҗбүри таләпләр күләме), интенсивлыгын һәм нәтиҗәләрен билгели торган зыян (зарар) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла, Контроль орган тарафыннан даими нигездә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү һәм идарә итү өчен файдаланыла торган белешмәләргә мониторинг (җыю, эшкәртү, анализ һәм исәпкә алу) үткәрелә.

2.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда зыян (зарар) китерү куркынычы белән идарә итү максатларында, контроль объектлары зыян (зарар) китерүнең түбәндәге риск категорияләренең берсенә (алга таба – риск категориясенә) кертелергә мөмкин:

-шактый зур куркыныч;
-урта куркыныч;
-уртача куркыныч;
-түбән куркыныч.

2.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын риск категорияләренә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы белән билгеләнгән.

2.4. Контроль объектын куркынычның бер категориясенә кертү ел саен аның характеристикаларын расланган риск критерийлары белән чагыштыру нигезендә Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы булып, контроль объекты параметрларына туры килү яисә кире читләшү, алар үзләре мәҗбүри таләпләрне бозмый, ләкин ихтимал югары дәрәҗәдә мондый бозулар һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы булуын раслый.

2.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркыныч индикаторлары исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында билгеләнгән.

2.6. Контроль объекты билгеле бер риск категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән риск категориясенә кертелгән дип санала.

2.7. Контроль орган контроль объектының куркынычның башка категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркыныч критерийларының үзгәрүе турында мәгълүмат кергән көннән биш эш көне эчендә контроль объектының куркыныч категориясен тиз арада үзгәртү турында карар кабул итә.

## 3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда үткәрелә торган профилактик чаралар төрләре

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, Контроль органы түбәндәге профилактик чаралар үткәрә:
1) мәгълүмат бирү;
2) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
3) кисәтү игълан итү;
4) консультация бирү;
5) профилактик визит.

### 3.1. Мәҗбүри таләпләрне үтәү һәм хокук куллану практикасын гомумиләштерү мәсьәләләре буенча контрольлек итүче һәм башка кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1.1. Контроль органы контрольдә торучы һәм башка кызыксынган затларга Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән мәгълүматларны урнаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча «Интернет» челтәрендәге Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт), массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт мәгълүмат системаларында (алар булганда) һәм башка рәвешләрдә контрольдә торучы затларның шәхси кабинетлары аша хәбәр итүне гамәлгә ашыра.

3.1.2. Муниципаль контрольне оештыру һәм үткәрү хокук куллану практикасын гомумиләштерү ел саен башкарыла.

Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча Контроль органы контроль органының хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре белән доклад әзерләүне тәэмин итә (алга таба – доклад).

Контроль орган доклад проекты буенча гавами фикер алышуны тәэмин итә.

Доклад контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында ел саен, хокук куллану практикасын гомумиләштерү елыннан соң килүче елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

### 3.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү игълан итү

3.2.1. Контроль органы контрольдә торучы затка әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр булган очракта һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы турында расланган белешмәләр булмаганда, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү игълан итә һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә.

3.2.2. Кисәтү Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә.

3.2.3. Контрольдә торучы зат кисәтү алган көннән соң 10 (ун) эш көне эчендә контроль органга кисәтүгә карата каршы килү бирергә хокуклы.

3.2.4. Каршы килүдә булырга тиеш:

1) каршы килү җибәрелә торган Контроль органы атамасы;

2) юридик затның исеме, шәхси эшмәкәр яки гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булганда), шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), контрольлек итүче затка җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) кисәтү датасы һәм номеры;

4) контрольдә торучы зат игълан ителгән кисәтүләр белән риза булмау нигезендә дәлилләр;

5) контрольдә торучы зат тарафыннан кисәтү алу датасы;

6) шәхси имза һәм дата.

3.2.5. Кирәк булган очракта, үз дәлилләрен раслау өчен, контрольдә торучы зат каршы килүгә тиешле документлар яки аларның расланган күчермәләрен терки.

3.2.6. Контроль органы аны алганнан соң унбиш эш көне эчендә кисәтүгә карата каршы килүне карый.

3.2.7. Каршы килүне карау нәтиҗәләре буенча Контроль органы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кисәтүне гамәлдән чыгару формасындагы каршы килүне канәгатьләндерә;

2) баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, каршы килүне канәгатьләндерүдән баш тарта.

3.2.8. Контроль органы контрольдә торучы затка каршы килүне карау нәтиҗәләре турында кисәтүгә карата каршы килүне караган көннән алып 5 (биш) эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

3.2.9. Шул ук нигезләр буенча каршы килүне кабат җибәрү рөхсәт ителми.

3.2.10. Контроль органы мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләрне исәпкә ала һәм башка профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү өчен тиешле мәгълүматларны куллана.

### 3.3. Консультация

3.3.1. Контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү вакыты;
3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү тәртибе;
4) Контроль органы карарларына шикаять бирү тәртибе.

3.3.2. Инспекторлар контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә консультацияләр бирә:

1) телефон буенча телдән аңлатмалар рәвешендә, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә яисә профилактик чара, контроль чара уздыру барышында;

2) рәсми сайтта контрольдә торучы затларның һәм аларның вәкилләренең Контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган бертиплы мөрәҗәгатьләр (10 нан артык бертиплы мөрәҗәгать) буенча язма аңлатма урнаштыру юлы белән.

3.3.3. Инспекторлар тарафыннан һәр мөрәҗәгать итүче шәхси кабул иткәндә шәхси консультацияләр 10 минуттан артмаска тиеш.

Телефон аша сөйләшү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

3.3.4. Контроль органы контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

3.3.5. Контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә язмача консультация бирү Контроль органы карарларына шикаять бирү тәртибендә гамәлгә ашырыла;

3.3.6. Контрольдә торучы зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән срокларда язма җавап бирү турында сорату җибәрергә хокуклы.

3.3.7. Контроль органы үткәрелгән консультацияләр исәбен алып бара.

## 3.4. Профилактик визит

3.4.1. Профилактика визиты инспектор тарафыннан контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә. Профилактик визит барышында контрольдә торучы затка үз эшчәнлегенә яисә үз карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч категорийларына туры килүе, куркыныч категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, шулай ук контроль объектына карата аны куркыныч категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә.

3.4.2. Профилактик визит барышында инспектор тарафыннан хәл ителергә мөмкин:

- «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 50 статьясында билгеләнгән тәртиптә контрольдә торучы затка консультация бирү;

- контроль объектларын куркыныч категориясенә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыю.

3.4.3. Инспектор мәҗбүри профилактик визитны түбәндәгеләргә карата үткәрә:

1) күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга керешүче контрольдә торучы затлар мондый эшчәнлек башланганнан бирле бер елдан да соңга калмыйча (эшчәнлек башлану турында мәгълүматлар булганда);

2) бик зур куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларын әлеге категориягә кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә торучы затка аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

3.4.4. Контрольдә торучы зат, бу хакта Контроль (күзәтчелек) органына аны үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, мәҗбүри профилактика визитын уздырудан баш тартырга хокуклы.

3.4.5. Инспектор тарафыннан профилактик визитлар елына кимендә 1 тапкыр үткәрелә. Визитның озынлыгы ике сәгатьтән артык була алмый.

3.4.6. Профилактика визитын үткәргәндә контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүгә турыдан-туры куркыныч тудыруы яки мондый зыян (зыян) китерелүе ачыкланса, инспектор контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карар кабул итү өчен бу хакта кичекмәстән контроль (күзәтчелек) органының вәкаләтле вазыйфаи затына хәбәр җибәрә.

3.4.7. Профилактика визиты нәтиҗәләре буенча инспектор әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә профилактика визиты үткәрү турында акт төзи.

3.4.8. Контроль органы үткәрелгән профилактик визитларның исәбен алып бара.

## 4. Муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган контроль чаралар

### 4.1. Контроль чаралар. Гомуми мәсьәләләр

4.1.1. Муниципаль контроль түбәндәге планлы һәм планнан тыш тикшерү чараларын үткәрүне оештыру юлы белән Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла:

-инспекция визиты, документар тикшерү, күчмә тикшерү - контрольдә торучы затлар белән үзара бәйләнештә булганда;

-мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшеренү – контрольдә торучы затлар белән бәйләнешсез.

4.1.2. Контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлек итү белән муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда:

-инспектор һәм контрольдә торучы зат яки аның вәкиле арасында очрашулар, телефон һәм башка сөйләшүләр (турыдан-туры бәйләнеш);

-документлар, башка материаллар соратып алу;

-инспекторның контрольдә торучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы (инспекторның һәркем өчен мөмкин булган җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш).

4.1.3. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә башкарыла торган контроль чаралар Контроль орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) Контроль органында зыян (зарар) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы яисә контроль объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәвен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү сроклары җитү;

3) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында йөкләмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248–ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында контроль органы карарын үтәү срогы чыгу.

Контроль чаралар контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затларының биремнәре, шул исәптән Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, Контроль органның эш планындагы биремнәрне дә кертеп, инспекторлар тарафыннан үзара бәйләнешсез үткәрелә.

4.1.4. Планлы һәм планнан тыш контроль чаралары, контрольдә торучы затлар белән үзара бәйләнешсез үткәрелә торган чаралардан тыш, инспектор һәм тикшерү

чарасын үткәрүгә җәлеп ителә торган затлар тарафыннан түбәндәге контроль гамәлләр башкару юлы белән үткәрелә:

карау;

сораштыру;

язма аңлатма алу;

документлар таләп итү;

экспертиза.

4.1.5. Контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнешне, шулай ук документар тикшерүне күздә тота торган контроль чара үткәрү өчен контроль органының вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган карары кабул ителә, анда Федераль законның 64 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләр, күчмә тикшеренү үтәлешенә күзәтү үткәрүгә карата Нигезләмәнең әлеге пунктында каралган контроль чарлар үткәрү турында карар кабул итү таләп ителми.

Контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турындагы карарларның формалары Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган.

4.1.6. Контроль чаралар Контроль органның контроль чараларын үткәрү турындагы карарында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан үткәрелә.

Кирәк булганда, Контроль органы тикшерү чараларын үткәрүгә экспертларны, билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән эксперт оешмаларын һәм контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары реестрына кертелгән экспертларны җәлеп итә.

4.1.7. Контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнешне күздә тоткан контроль чарасын үткәрү тәмамланганнан соң, инспектор контроль чарасы актын (алга таба – акт) төзи, ул Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә.

Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә.

Контроль чарасы тәмамланганга кадәр контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнешне күздә тотучы ачыкланган бозулар бетерелгән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә.

4.1.8. Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлиле булган документлар, башка материаллар актка теркәлә.

Тикшерү чарасын уздырганда тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлергә тиеш.

4.1.9. Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урыны буенча башкарыла.

4.1.10. Дәүләт, коммерция, хезмәт, башка серләрне тәшкил иткән контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

4.1.11. Контроль (күзәтчелек) чарасы актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контрольдә торучы зат әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган тәртиптә актка шикаять бирергә хокуклы.

### 4.2. Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча контроль орган тарафыннан кабул ителә торган чаралар

4.2.1. Контроль органы контроль чарасы үткәргәндә контрольдә торучы зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта бурычлы:

1) контроль чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә торучы затка мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) бирергә, аларны бетерүнең тиешле срокларын күрсәтеп, ләкин алты айдан да артык түгел (документар тикшерү уздырганда күрсәтмә контрольдә торучы затка документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә) һәм (яисә) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында, шулай ук контроль төрләре турында федераль законда каралган башка чараларны үткәрү турында;

2) биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, урыннарны, җайланмаларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (куллануны) тыю турында таләп белән судка кадәр мөрәҗәгать итүгә кадәр закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне (зарар) булдырмау яисә аның китерүен туктату буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә һәм гражданнарга, оешмаларга закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы булу турындаһәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле ысул белән мәгълүмат җиткерергә, әгәр тикшерү барышында контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы гражданин, оешмаларның эшчәнлеге, алар тарафыннан эксплуатацияләнә (кулланыла) торган биналар, төзелмәләр, корылмалар, урыннар, җайланмалар, транспорт чаралары һәм башка шундый объектлар, җитештерелә торган һәм сатыла торган товарлар, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүнең турыдан-туры куркынычы яки мондый зыян (зарар) китерелгән дип билгеләнсә;

3) контроль (күзәтчелек) чарасы барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләрен ачыклаганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә яисә тиешле вәкаләтләр булганда, гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүгә, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүгә, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмауга контрольне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә, күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать иткәнче, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса;

5) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, башка чаралар үткәрү буенча тәкъдимнәр бирү турындагы мәсьәләне карарга.

Күрсәтмә әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә форма буенча 2 данәдә Контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан төзелә.

4.2.2. Күрсәтмәнең үтәлү срогы чыкканчы, контрольдә торучы зат күрсәтмәнең үтәлеше турында, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне раслаучы документлар һәм белешмәләр кушып, контроль органына хәбәр итә.

4.2.3. Контрольдә торучы зат әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә кабул ителгән карарның үтәлү срогы чыккач, яисә күрсәтелгән карар белән билгеләнгән документларны һәм белешмәләрне контрольдә торучы зат тарафыннан тапшырганда яисә мәҗбүри таләпләрнең (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәтү кысаларында мәгълүмат алган очракта, Контроль органы карарның бирелгән документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә үтәлешен бәяли.

4.2.4. Күрсәтмәне контрольдә торучы зат тарафыннан үтәү очрагында, Контроль органы контрольдә торучы затка күрсәтмәнең үтәлүе турында хәбәрнамә җибәрә.

4.2.5. Күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр контрольдә торучы зат тарафыннан алар нигезендә яисә мәҗбүри таләпләрне (куркынычсызлык мониторингы) үтәүне күзәтү кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә тапшырылмаса, карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин түгел, контроль органы әлеге карарның үтәлешен инспекция визиты яки документар тикшерү юлы белән бәяли.

Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның үтәлешенә бәя бирелгән очракта, күчмә тикшерү үткәрергә рөхсәт ителә.

4.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 4.2.6 пунктында каралган контроль чараны үткәрү нәтиҗәләре буенча контроль органы карарның үтәлмәве яки тиешенчә үтәлмәве ачыкланса, ул әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 1 пунктчасында каралган карарны, аны үтәүнең яңа срокларын күрсәтеп, янә контрольдә торучы затка тапшыра.

Күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, Контроль органы, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрә.

## 4.3. Планлы контроль чаралары

4.3.1. Планлы контроль чаралары чираттагы календарь елына контроль органы тарафыннан төзелә торган һәм прокуратура органнары белән килештерелергә тиешле планлы тикшерү чаралары планы (алга таба – еллык чаралар планы) нигезендә үткәрелә.

4.3.2. Куркынычның аерым категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата планлы тикшерү чаралары үткәрү төрләре, вакыты зыян (зарар) китерү куркынычы белән билгеләнә.

4.3.3. Контроль органы планлы тикшерү чараларының түбәндәге төрләрен үткәрергә мөмкин:

-инспекция визиты;

-документар тикшерү;

-күчмә тикшерү.

Югары куркыныч категориясенә керүче объектларга карата инспекция визиты, документар тикшерү, күчмә тикшерү үткәрелә.

Урта куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата документар тикшерү, күчмә тикшерү үткәрелә.

Уртача куркыныч категориясенә керүче объектларга карата документар тикшерү, күчмә тикшерү үткәрелә.

4.3.4. Контроль объектларына карата планлы тикшерү чараларын түбәндәге түбәндәге кабатланып торган чорларда үткәрелә:

-бик зур куркыныч категориясе өчен – 2 елга бер тапкыр;

-урта куркыныч категориясе өчен – 3 елга бер тапкыр;

-уртача куркыныч категориясе өчен – 5 елга бер тапкыр.

Түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектына карата планлы контроль чаралары үткәрелми.

4.3.5. Гражданнар файдалана торган торак урыннарына карата муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда, планлы тикшерү чаралары үткәрелми.

## 4.4. Планнан тыш контроль чаралары

4.4.1. Планнан тыш контроль чаралары документар һәм күчмә тикшерүләр, инспекция визиты, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшеренү рәвешендә үткәрелә.

4.4.2. Планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү турындагы карар мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын исәпкә алып кабул ителә.

4.4.3. Планнан тыш контроль чаралары, үзара бәйләнешсез планнан тыш тикшерү

чараларыннан тыш, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3-5 пунктларында каралган нигезләр буенча үткәрелә.

4.4.4. Планнан тыш тикшерү чарасы прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин булса, әлеге чара мондый килешүдән соң үткәрелә.

## 4.5. Документар тикшерү

4.5.1. Документар тикшерү астында Контроль органының урнашу урыны буенча үткәрелә торган контроль чара аңлашыла, аның предметы - контрольдә торучы затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләр, шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм контроль (күзәтчелек) органының мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар.

4.5.2. Контроль органы карамагында булган документларда булган белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудыра яки бу белешмәләр контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, контроль органы контрольдә торучы зат адресына документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Әлеге таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә контрольдә торучы зат таләпләрдә күрсәтелгән документларны контроль органга җибәрергә тиеш.

4.5.3. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш.

Күрсәтелгән срокка түбәндәге моменттан чор кертелми:

1) контроль орган тарафыннан контрольдә торучы затка, таләптә күрсәтелгән документларны контроль органга тапшырганчы, документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тикшерү органына җибәрү таләбе;

2) контрольдә торучы затка Контроль органы мәгълүматын җибәргәннән соң чор:

-контрольдә торучы зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыкларны ачыклау турында;

-бирелгән документлардагы белешмәләрнең контроль органында булган һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган документлардагы белешмәләргә туры килмәве турында һәм күрсәтелгән аңлатмаларны Контроль органга тапшырган чорга кадәр, кирәкле аңлатмаларны язма рәвештә тапшыру таләбе.

4.5.4. Документар тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) язмача аңлатмалар алу;

2) документлар таләп итү;

3) экспертиза.

4.5.5. Язма аңлатмалар инспектор тарафыннан контрольдә торучы заттан яки аның вәкиленнән, шаһитлардан соратып алынырга мөмкин.

Күрсәтелгән затлар инспекторга тикшерү тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча ирекле формада язма аңлатмалар бирә.

Язма аңлатмалар ирекле формада язма документ төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Инспектор вазыйфаи затлар яки оешма хезмәткәрләре, контрольдә торучы зат булган гражданиннан, аларның вәкилләре, шаһитлар сүзләреннән язмача аңлатмалар төзергә хокуклы. Бу очракта күрсәтелгән затлар аңлатмалар белән танышалар, кирәк булганда текстны тулыландыралар, инспекторның аларның сүзләреннән дөрес язуы турында билге ясыйлар һәм аны төзү датасын һәм урынын күрсәтеп, документка кул куялар.

4.5.6. Контроль чара үткәрү барышында, инспектор контрольдә торучы затка контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне уздыру өчен кирәкле һәм (яки) әһәмияткә ия булган документлар һәм (яки) аларның күчермәләре, шул исәптән фотога төшерү, аудио - һәм видеоязмалар, мәгълүмат базалары, мәгълүмат

банклары, шулай ук мәгълүмат туплагычны тапшыру турында таләпләрне тапшырырга (җибәрергә) хокуклы.

Контрольдә торучы зат документлар тапшыру турында таләптә күрсәтелгән срокта сорала торган документларны Контроль органга җибәрә яисә кичекмәстән язма рәвештә юллама белән, контрольдә торучы зат кирәкле документларны шул вакыт эчендә тапшыра алмавының сәбәпләрен һәм срокларын күрсәтеп, документларны билгеләнгән вакытта тапшыра алмавы турында инспекторга хәбәр итә.

Фотога төшерү, аудио - һәм видеоязма материалларына, мәгълүмат базаларына, мәгълүмат банкларына, шулай ук мәгълүмат туплагычларга керү аларга документар тикшерү уздыру вакытына контроль чаралар үткәрү өчен кирәк булган мәгълүматны карау һәм эзләү хокукы белән логин һәм пароль рәвешендә бирелә.

4.5.7. Экспертиза контроль орган кушуы буенча эксперт яки эксперт оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Экспертиза контрольдә торучы затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча да, шулай ук эксперт яки эксперт оешмасы эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча да башкарылырга мөмкин.

Экспертизаны гамәлгә ашыру вакыты экспертиза төренә бәйле һәм контрольлек органы белән эксперт яки эксперт оешмасы арасындагы килешү буенча һәр конкрет очракта аерым билгеләнә.

Экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсе белән контроль орган тарафыннан расланган форма буенча рәсмиләштерелә.

4.5.8. Документар тикшерү актын рәсмиләштерү документар тикшерү уздырган көнне Контроль органның урнашкан урыны буенча башкарыла.

4.5.9. Акт контрольдә торучы затка Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә генә үткәрелә.

## 4.6. Күчмә тикшерү

4.6.1. Күчмә тикшерү астында әлеге Федераль закон максатларында җитештерү объектларына ия һәм (яки) алардан файдаланучы конкрет контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнеш аша, мондый зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү, шулай ук контроль (күзәтчелек) органы карарларының үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә торган комплекслы контроль (күзәтчелек) чарасы аңлашыла.

4.6.2. Күчмә тикшерү контрольдә торучы затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

Күчмә тикшерү дистанцион багланышлар чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә ярдәмендә үткәрелергә мөмкин.

4.6.3. Күчмә тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) контроль органы карамагында булган яки ул соратып ала торган документларда һәм контрольдә торучы затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгы һәм дөреслегенә ышанырга;

2) контрольдә торучы затның һәм (яки) аның карамагындагы һәм (яки) кулланылучы контроль объектларының әлеге Нигезләмәнең 4.6.2 пунктының беренче өлешендә күрсәтелгән урынга чыкмыйча гына эшчәнлегенең, гамәлләренең (гамәл кылмавының) мәҗбүри таләпләргә туры килүен һәм башка тикшерү чаралары кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләр кылуны бәяләргә.

4.6.4. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5

пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш, үткәрелергә мөмкин.

4.6.5. Контроль органы контрольдә торучы затка күчмә тикшерүне үткәрү турында, күчмә тикшерүне үткәрү турындагы карарның күчермәләрен контрольдә торучы затка җибәрү юлы белән, ул башланганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

4.6.6. Инспектор күчмә тикшерү уздырганда, контрольдә торучы затка (аның вәкиленә) хезмәт таныклыгын, күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарның күчермәсен күрсәтә, шулай ук контроль чараларның бердәм реестрындагы хисап номерын хәбәр итә.

4.6.7. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмый.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата күчмә тикшерү барышында үзара хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

4.6.8. Күчмә тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау;

2) сораштыру;

3) язма аңлатма алу;

4) документлар таләп итү;

5) экспертиза.

4.6.9. Карау инспектор тарафыннан контрольдә торучы зат һәм (яки) аның вәкиле булганда мәҗбүри рәвештә видеоязма кулланып гамәлгә ашырыла.

Контроль органының вазыйфаи затлары (инспектор) тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә карау беркетмәсе төзелә, бер нөсхәсе контрольдә торучы затка һәм (яки) аның вәкиленә тапшырыла.

4.6.10. Сораштыру астында инспектор тарафыннан контрольдә торучы заттан яисә аның вәкиленнән һәм мондый мәгълүмат булган башка затлардан контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне уздыру өчен әһәмиятле телдән мәгълүмат алудан гыйбарәт контроль гамәл аңлашыла.

Сораштыру нәтиҗәләре сораштыру беркетмәсендә теркәлә, ул сораштырыла торган зат тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген раслый, шулай ук контроль чара актында алынган белешмәләр тикшерү чарасы өчен зур әһәмияткә ия булган очракта теркәлә.

4.6.11. Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү, сораштыру үткәргәндә, инспектор мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудио - һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка алымнарын кулланырга хокуклы.

Фотога төшерү ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының һәркайсының икедән дә ким булмаган рәсеме белән башкарыла.

Фотога төшерү һәм видеоязмаларны мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен куллану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.6.12. Контрольдә торучы зат тарафыннан таләп ителә торган документларны, язмача аңлатмаларны тапшыру, экспертиза үткәрү әлеге Нигезләмәнең 4.5.5, 4.5.6 һәм 4.5.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.6.13. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң инспектор күчмә тикшерү акты төзи.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма үткәрү турындагы мәгълүмат тикшерү актында чагылдырыла.

Актны дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша чыгып тикшерү үткәргән очракта, Нигезләмәнең әлеге пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән нигезләмә кулланылмый.

4.6.14. Күчмә тикшерүне үткәрү, урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча контрольдә торучы зат булмау сәбәпле, яисә контрольдә торучы зат эшчәнлегенең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, яисә күчмә тикшерүне үткәрү яисә тәмамлау мөмкинлегенә китергән контрольдә торучы затның бүтән гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле рәвештә мөмкин булмаса, инспектор, сәбәпләрен күрсәтеп, күчмә тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи һәм контрольдә торучы затка Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә контроль чаралар үткәрү мөмкинлеге булмау турында хәбәр итә.

Бу очракта инспектор күчмә тикшерү тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта, күчмә тикшерү үткәрү чоры кысаларында контроль гамәлләр кылырга хокуклы.

4.6.15. Контрольдә торучы зат булган шәхси эшмәкәр, гражданин Контроль органына контроль чаралар үткәргәндә түбәндәге очракларда була алмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

2) судлар, хокук саклау органнары, хәрби комиссариатлар чакыруы (хәбәрнамәләр, повесткалар) буенча килү зарурилыгы;

3) Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә аларга карата контроль чаралар үткәргәндә катнашу мөмкинлеген булдырмый торган чикләү чараларын сайлау;

4) хезмәт командировкасында булу.

Югарыда күрсәтелгән мәгълүмат кергән очракта, контроль чаралар үткәрү тикшерү органы тарафыннан тикшерүне күчерү өчен сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

## 4.7. Инспекция визиты

4.7.1. Инспекция визиты астында әлеге Федераль закон максатларында конкрет контрольдә торучы зат һәм (яки) җитештерү объектының хуҗасы (кулланучысы) белән үзара хезмәттәшлек юлы белән үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы аңлашыла.

4.7.2. Инспекция визиты контрольдә торучы затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

Инспекция визиты әлеге Нигезләмәнең 1.3.3 пунктында күрсәтелгән контрольдә торучы затка һәм объектларның милекчеләренә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Контрольдә торучы затлар яки аларның вәкилләре инспекторның биналарга, корылмаларга, урыннарга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Инспекция визитын үткәрү вакыты эшчәнлек алып баруның бер урынында яисә бер җитештерү объектында (территориядә) бер эш көненнән артмый.

4.7.3. Инспекция визиты барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

а) карау;

б) сораштыру;

в) язмача аңлатмалар алу;

г) мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә торучы затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны таләп итү.

Инспекция визитын дистанцион бәйләнеш чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша үткәрергә рөхсәт ителә.

4.7.4. Планнан тыш инспекция визиты бары тик прокуратура органнары белән килештереп, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш, үткәрелергә мөмкин.

4.7.5. Әлеге Нигезләмәнең 4.7.3 пунктында каралган контроль гамәлләр әлеге

Нигезләмәнең 4.5.5, 4.5.6, 4.6.8 - 4.6.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 4.8. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы)

4.8.1. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү астында (куркынычсызлык мониторингы) әлеге Федераль закон максатларында контроль (күзәтчелек) органында булган контроль объектлары турында, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдә торучы затлар тарафыннан тапшырылган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән, башка һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автомат режимда эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлау.

4.8.2. Контроль органы, мәҗбүри таләпләрнең (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәткәндә, Контроль органында булган контроль объектлары турында, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдә торучы затлар тарафыннан тапшырылган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән, башка һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автомат режимда эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлауны үткәрә.

4.8.3. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәтү барышында зыян (зарар) китерү яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар) куркынычы янау, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне бозуга әзерләнү турында яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында фактлар ачыкланса, контроль органы тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

1) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы нигезендә планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карар;

2) кисәтү игълан итү турында карар;

3) Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә, мондый мөмкинлекне Федераль законда контроль төре турында, Россия Федерациясе субъекты законында контроль төре турында күрсәткән очракта, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар;

4) Мондый мөмкинлекне контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты Законында күрсәткән очракта, Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Татарстан Республикасы Законында беркетелгән карар.

### 4.9. Күчмә тикшеренү

4.9.1. Күчмә тикшерү астында әлеге Федераль закон максатларында контрольдә торучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы аңлашыла.

4.9.2. Күчмә тикшерү оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) урнашкан (эшчәнлек алып бару), гражданинның эшчәнлек алып бару урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдә торучы зат белән хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

Күчмә тикшерү барышында әлеге Нигезләмәнең 1.3. пунктында күрсәтелгән барлык кеше дә керә ала торган объектларда (чикләнмәгән затлар даирәсе керү өчен ачык булган) карау гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4.9.3. Күчмә тикшерү контрольдә торучы затка хәбәр итмичә үткәрелә.

Бер объектка (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектка) күчмә тикшерү уздыру вакыты, әгәр контроль төре турында Федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, бер эш көненнән дә артмый.

Күрсәтелгән контроль чараны үткәрү нәтиҗәләре буенча Контроль органының вазыйфаи заты әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасындагы форма буенча күчмә тикшерү акты төзи.

4.9.4. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

## 5. Контроль орган һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

Контроль органының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына), Контроль органның муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контрольдә торучы затларның хокукларын бозуга китергән карарларына Россия Федерациясе законнары нигезендә контрольдә торучы зат тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## 6. Контроль төренең төп һәм индикатив күрсәткечләре һәм муниципаль контроль өчен аларның максатчан кыйммәте

Муниципаль контрольнең төп һәм индикатив күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәте әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында билгеләнгән.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәре
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркынычлык категорияләренә кертү критерийлары

1. Контроль объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү куркыныч күрсәткече кыйммәтенә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла:

куркыныч күрсәткеченең кыйммәте 6 дан артык булганда, контроль объекты югары куркыныч категориясенә керә;

күркыныч күрсәткеченең кыйммәте 4 тән 6 га кадәр булганда - урта куркыныч категориясенә;

куркыныч күрсәткеченең кыйммәте 2 дән 3 кә кадәр булганда - уртача куркыныч категориясенә;

куркыныч күрсәткеченең кыйммәте 0 дән 1 гә кадәр булганда, түбән риск категориясенә керә.

2. Куркыныч күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$K = 2 \times V_1 + V_2 + 2 \times V_3$, кайда:

К – куркыныч күрсәткече;

$V_1$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән ел алдыннан килгән ике календарь елда законлы көченә кергән карарлар (алга таба - эшчәнлекне куркыныч категориясенә кертү турында карар), Контроль орган тарафыннан төзелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4.1 статьясында каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү турында карарлар саны;

$V_2$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән ел алдыннан килгән ике календарь елда законлы көченә кергән карарлар, Контроль орган тарафыннан төзелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.21-7.23 статьяларында, 9.16 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү турында карарлар саны;

$V_3$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән ел алдыннан килгән ике календарь елда законлы көченә кергән карарлар, Контроль орган тарафыннан төзелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү турында карарлар саны.

Түбән Кама шәһәре
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Контроль органына күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре булган гражданнар яки оешма, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучылар булган гражданнар мөрәҗәгате, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контрольдә торучы затның эшчәнлегендә түбәндәге мәҗбүри таләпләрдән бер генә булса да тайпылу турында мәгълүмат керү:

а) күпфатирлы йортта торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе;

б) күпфатирлы йортта урыннарны яңадан планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе;

в) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү;

г) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен урыннарга керү мөмкинлеген тәэмин итү;

д) күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларның авария-диспетчерлык хезмәтен гамәлгә ашыру өлешендә эшчәнлеге;

е) йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларын кулланганда һәм карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү.

Әлеге индикаторы булуы закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүнең турыдан-туры янавын күрсәтә һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә, кичекмәстән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү өчен нигез булып тора.

2. Контроль органына күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре булган гражданнар яки оешма, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучылар булган гражданнар мөрәҗәгате, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат, әлеге типик индикаторларның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдән һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә, планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрдән тыш, әгәр әлеге мөрәҗәгать килгәнчегә кадәр бер ел дәвамында Контроль органы тарафыннан контрольдә торучы затка шундый ук мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куелмау турында кисәтүләр игълан ителгән булса.

3. Контроль органы адресына күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре булган гражданнар яки оешма, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучылар булган гражданнардан кергән мөрәҗәгать, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында кергән мәгълүмат саны узган елның шул ук чоры һәм (яки) узган календарь елының шул ук чоры белән чагыштырганда, бер үк вакыт берәмлегенә (ай, алты ай, унике ай) ике тапкыр һәм аннан күбрәк арткан.

4. Өч ай дәвамында күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре булган гражданнар яки оешма, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучылар булган гражданнардан кергән белешмәләрнең, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә

органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматның һәм торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә торучы зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүматның (белешмәләрнең) туры килмәвенең өч ай эчендә 5 тән артык фактын ачыклау.

Түбән Кама шәһәре
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

Контроль органы акты формасы

Контроль органы бланкы

______________________________
(контрольдә торучы зат җитәкчесе
вазыйфасы күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы затның
тулы исеме күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы зат
җитәкчесенең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булганда) күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы затның
урнашу урыны адресы күрсәтелә)

Профилактика визиты акты № _______

________________ «___» _________20__ ел
(төзү урыны)

Профилактика визиты

______________________________________________________________________
(юридик затның, шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)
____________________________________________________________________карата үткәрелгән

ИНН
_____________________________________________________________________________
(юридик зат, шәхси эшкуар өчен)
Яшәү адресы: ________________________________________________________________
(гражданинның теркәлү адресы һәм фактта яшәү урыны)
_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(почта индексы, өлкә, шәһәр, урам, йорт)
_______________________________________________________________адресы буенча урнашкан

Профилактика визиты муниципаль контроль турындагы нигезләмә кысаларында үткәрелде
______________________________________________________________________
(контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән)
_____сәгать _____мин. - ______сәгать _____мин.
Профилактика визиты үткәрүдә катнашты ________________________________________
_____________________________________________________________________________

(җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

Контрольдә торучы затның эшчәнлек төре: ________________________________________

Контроль объекты төрләре:

________________________________________________________________________________

(«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге)

________________________________________________________________________________

________ һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның

16 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган контроль объектлары төрләре арасыннан күрсәтелә)

Контроль объектларының куркыныч категориясе:

_____________________________________________

Профилактика визиты түбәндәге вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелгән:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Профилактик визит үткәрү барышында түбәндәге мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрелде (консультацияләр үткәрелгән очракта): __________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Профилактика визиты үткәрү нәтиҗәләре буенча:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

(контрольдә торучы затка аның эшчәнлегенә яисә аның карамагында булган контроль объектына карата куела торган

мәҗбүри таләпләр, аларның куркынычлылык критерийларына туры килүе, нигезләр һәм куркынычлылык категориясен

киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары турында, шулай ук контроль объектына карата аны риск категориясенә керүдән чыгып

үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында хәбәр итәргә күрсәтмә;

профилактика визиты нәтиҗәләре буенча контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүгә

турыдан-туры куркыныч тудыруы яки мондый зыян (зарар) китерелгәне ачыкланса, норматив хокукый акт таләпләрен

билгели торган сылтама белән ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары күрсәтелә)

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Кушымта итеп бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Профилактика визиты үткәргән затларның имзалары: ______________________________

________________________________________________________________________________

Профилактика визиты үткәрү акты белән таныштым, актның күчермәсен барлык кушымталар белән алдым: ______________________________________________________

________________________________________________________________________________

( җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе исеме, атасының исеме (соңгысы — булган очракта)

«__» _______20__ел ____________

(имза)

Түбән Кама шәһәре
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә
4 нче кушымта

Контроль органы күрсәтмәсе формасы

Контроль органы бланкы ___________________________________
___________________________________
(контрольдә торучы зат җитәкчесе вазыйфасы күрсәтелә)
___________________________________
(контрольдә торучы затның тулы исеме күрсәтелә)
___________________________________
(контрольдә торучы зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) күрсәтелә)
___________________________________
(контрольдә торучы затның урнашу урыны адресы күрсәтелә)

КҮРСӘТМӘ

_______________________________________________________________________
*(контрольдә торучы затның тулы исеме күрсәтелә)*
ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында

_______________________________________________________тарафыннан үткәрелгән
*(контроль органының тулы исеме күрсәтелә)*
_________________________________________________________________карата
*(контрольдә торучы затның тулы исеме күрсәтелә)*
«__» _________________ 20__ ел - «__» _________________ 20__ ел чорында

________________________________________________________________нигезендә
*(контроль чараны үткәрү турында тикшерү органы актының исеме һәм реквизитлары күрсәтелә)*
______________________________________________________нәтиҗәләр буенча,
*(контроль орган карары нигезендә контроль чараның төре һәм формасы күрсәтелә)*

________________ закон буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланды:
*(әлеге мәҗбүри таләпләр билгеләнгән норматив хокукый актларнын структур берәмлекләрен күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары санала)*

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә
_____________________________________________________________________________
*(контроль органының тулы исеме күрсәтелә)*

Күрсәтмә бирә:
1. «______» ______________ 20_____ елга кадәр ачыкланган мәҗбүри таләпләрне

бозуны бетерергә.
2. «__» _______________ 20_____ елга кадәр ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәү турында, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне раслаучы документлар һәм белешмәләрне кушып,

______________________________________________________________________
*(контроль органының тулы исеме күрсәтелә)*
хәбәр итәргә.

Әлеге күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлмәве Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (контроль чаралар үткәрүгә вазыйфаи зат имзасы) | (контроль чаралар үткәрүгә вәкаләтле вәкаләтле зат вазыйфасы) | (контроль чаралар үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) |

Түбән Кама шәһәре
территориясендә
муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә
5 нче кушымта

Контроль органы акты формасы

Контроль органы бланкы

____________________________________
(контрольдә торучы зат җитәкчесе
вазыйфасы күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы затның
тулы исеме күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы зат
җитәкчесенең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булганда) күрсәтелә)

_________________________________
(контрольдә торучы затның
урнашу урыны адресы күрсәтелә)

Күчмә тикшеренү акты № _______

__________________ «___» __________20__ ел
(төзү урыны)

Күчмә тикшеренү

____________________________________________________________________________
(юридик затның, шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)
____________________________________________________________карата үткәрелгән

ИНН
_________________________________________________________________________
(юридик зат, шәхси эшкуар өчен)
Яшәү адресы: ______________________________________________________
(гражданинның теркәлү адресы һәм фактта яшәү урыны)
_________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________
(почта индексы, өлкә, шәһәр, урам, йорт)
_______________________________________________________адресы буенча урнашкан

Күчмә тикшеренү муниципаль контроль турындагы нигезләмә кысаларында үткәрелде
______________________________________________________________________
(контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән)
_____сәгать _____мин. - ______сәгать _____мин.

Күчмә тикшеренү үткәрүдә катнашты ___________________________

____________________________________________________________________________
(җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
Контрольдә торучы затның эшчәнлек төре: _______________________________________

Контроль объекты төрләре:

____________________________________________________

(«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге)

________________________________________________________________________

һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның

________________________________________________________________________

16 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган контроль объектлары төрләре арасыннан күрсәтелә)

Контроль объектларының куркыныч категориясе:

__________________________________________

Күчмә тикшеренү түбәндәге вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелгән:

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Рейд каравы үткәрү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре үткәрелде:

1) карау ________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Аның нәтиҗәләре буенча төзелде:

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Күчмә тикшеренү нәтиҗәләре буенча контрольдә торучы затның контроль объектына карата билгеләнде:

________________________________________________________________________

(күчмә тикшеренү нәтиҗәләре буенча нәтиҗәләр күрсәтелә)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

_________________________________________

Кушымта итеп бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

______

Күчмә тикшеренү үткәргән затларның имзалары: ________________________

________________________________________________________________________

«__»_______20__ел

____________

(имза)

Түбән Кама шәһәре
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Муниципаль торак контроленең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре исемлеге

| Күрсәткеч номеры | Күрсәткеч исеме | Исәпләү формуласы | Шәрехләр (кыйммәтләрне интерпретацияләү) | Күрсәткечнең база кыйммәте | Күрсәткечне халыкара чагыштыру | Күрсәткечнең максатчан кыйммәте | | | Күрсәткеч кыйммәтен билгеләү өчен мәгълүмат чыганаклары | Күрсәткечне үз эченә алган стратегик планлаштыру документлары турында белешмәләр (булганда) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Узган ел | Агымдагы ел | Киләсе ел | | |
| | ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘР | | | | | | | | | |
| 1 | Законда саклана торган кыйммәтләргә зыянны (зарарны) минимальләштерү дәрәҗәсен, зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсен чагылдыра торган күрсәткечләр | | | | | | | | | |
| 1.1. | Күпфатирлы йортларда һәм торак йортлардагы урыннарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу | Сп*100/ ВРП | Сп- күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары: күрсәтмәләр журналы, тикшерүләр реестры, статистик мәгълүматлар | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нәтиҗәсендә гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә китерелгән матди зыян, тулаем региональ продукттан процентларда | | гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә законсыз исәпләнгән түләүне яңадан исәпләү суммалары, млн. сум;<br>ВРП - расланган тулаем региональ продукты, млн. сум.<br>Күрсәткечнең төгәллеге 1 йөздән дә ким булмаган (өтердән соң ике билге) күрсәткече исәпкә алына, төгәллеге 1 йөздән дә ким булмаган күрсәткечләр нульгә тиңләштерелә. | | | | | | | |
| 1.2. | Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салуга китергән мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының ачыкланган бозуларның гомуми саныннан ачыкланган өлеше | Кспв*100% / Ксн | Кспв - закон көченә кергән суд карарлары белән расланган гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салуга китергән мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының ачыкланган саны;<br><br>К сн- тикшерү | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары; «Гадел хөкем» РФ ДАС мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | нәтиҗәләре буенча ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының гомуми саны | | | | | | | |
| | ИНДИКАТИВ КҮРСӘТКЕЧЛӘР | | | | | | | | | |
| 2 | Контроль эшчәнлеге мониторингы, аны анализлау, аны тормышка ашырганда барлыкка килгән проблемаларны ачыклау һәм зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән хезмәт, матди һәм финанс ресурслары күләме арасындагы нисбәтне характерлый торган сәбәпләрнең барлыкка килүен билгеләү өчен кулланыла торган күрсәткечләр, шулай ук контрольдә торучы затлар эшчәнлегенә тыкшыну дәрәҗәсе | | | | | | | | | |
| | 2.1. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә контроль чаралар | | | | | | | | | |
| 2.1.1. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми санына карата билгеләнгән вакытта үткәрелгән муниципаль торак контроле кысаларында контроль чаралар өлеше | Пву*100 % / Пок | Пву –билгеләнгән вакытта үткәрелгән муниципаль торак контроле кысаларында контроль чаралар саны<br><br>Пок – муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.2. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәләрнең | ПРн*100% / ПРо | ПРн- суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләрнең саны;<br><br>Про- муниципаль | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомуми санына карата суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләрнең өлеше | | торак контролен гамәлгә ашыру барышында бирелгән күрсәтмәләрнең гомуми саны | | | | | | | |
| 2.1.3. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларның өлеше | Ппн*100 % / Пок | Ппн –нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган контроль чаралар саны;<br>Пок - муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.4. | Үткәрелгән контроль чараларның гомуми санынннан, аларны үткәрү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып, аларны ачыклау нәтиҗәләре буенча мондый контроль чараларын гамәлгә ашыручы муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата | Псн*100 % /Пок | Псн -<br>аларны үткәрү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып, аларны ачыклау нәтиҗәләре буенча мондый контроль чараларын гамәлгә ашыручы муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата дисциплинар, административ җәза чаралары | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дисциплинар, административ җәза чаралары кулланылган муниципаль торак контроле органы тарафыннан үткәрелгән контроль чараларның өлеше | | кулланылган муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларның саны<br><br>Пок- муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны | | | | | | | |
| | 2.2. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек итмичә контроль буенча чаралар | | | | | | | | | |
| 2.2.1. | Контроль чараларның гомуми саны | Инспекциянең статистик мәгълүматлары | Муниципаль торак контроле органнарының статистик мәгълүматлары | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |
| 2.2.2. | Контроль чаралары нәтиҗәләре буенча муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәләрнең гомуми санына карата суд тәртибендә законсыз дип табылган | ПРМБВн*100% / ПРМБВо | ПРМБВн – суд тәртибендә законсыз дип табылган контроль чаралары нәтиҗәләре буенча муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәләр саны | | | | | | Контроль органының статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтмәләрнең өлеше | | ПРМБВо - контроль чаралары нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәләр саны | | | | | | | |